**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 июнь № 472

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел,11 март, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«үзенең компетенциясе чикләрендә экстремистлар эшчәнлегенә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларны террорчылыктан саклауны тәэмин итә;

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау программасы кысаларында, үзенең компетенциясе чикләрендә мәгълүмат җыюны

һәм аны дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мәдәният тармагында мәнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органына тапшыруны тормышка ашыра.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\472.docx